**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы**
**Кәркәүч авыл җирлеге башлыгы**
**КАРАРЫ**

**11 ноябрь 2024 ел** **№ 4**

**«Кукмара муниципаль районы Кәркәүч авыл җирлегенең Бурсык-Елга авылы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Кәркәүч авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2024 елның 21 ноябренә 10 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Кәркәүч авыл җирлегенең Бурсык-Елга авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Бурсык-Елга авылы, 1 Май урамы, 30а нче йорт адресы буенча урнашкан авыл мәчете бинасында үткәрергә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, I төркем инвалидлары, 18 яшькә кадәрге 4 һәм аннан да күбрәк баласы булган күп балалы гаиләләр, 85 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге пенсионерлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзалары кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кәркәүч авыл җирлегенең Бурсык-Елга авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2025 елда үзара салымны 1000 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (вак таш белән капланган юлларны төзү, ремонтлау һәм төзекләндерү, траншеяларны экскаватор белән эшләү, проект-смета документациясен эшләү һәм технадзорны гамәлгә ашыру, юлларны төзекләндерү, карап тоту һәм төзекләндерүнең башка төрләре);

- урамнарны яктырту җайланмасы (урамнарны яктыртуны карап тоту, комплектлаучы әйберләр сатып алу һәм урнаштыру, урамнарны яктыртуны карап тоту буенча башка төр эшләр);

- торак пункт территориясен төзекләндерү (Бөрсык-Елга авылы территориясен төзекләндерү, юлларны кардан чистарту, проект-смета документациясен эшләү һәм технадзорны гамәлгә ашыру, башка төр эшләр);

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Гражданнар җыенын үткәрү өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча (урамнар буенча) бүләргә.

4. Гражданнар җыенын оештыручы итеп, Кәркәүч авылы Башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Кәркәүч авыл
җирлеге башлыгы

М.Ф.Зайнутдинов